Татарстан Республикасы Президенты Указы

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законының 16, 29 һәм 37 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Расларга:

«Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медаленә таныклык формасын (үрнәген) (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү өчен бүләкләү кәгазе формасын (3 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Президентының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү документларын карау һәм тапшыру тәртибе турында» 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-828 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 23 июлендәге ПУ-494 номерлы һәм 2009 елның 27 февралендәге ПУ-106 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү документларын карау һәм тапшыру тәртибе турындагы Нигезләмәне (кушымтада бирелә) расларга.»;

б) Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү өчен бүләкләү кәгазе формасын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указ белән расланган тасвирлама һәм форма (үрнәкләр) нигезендә «Ана даны – Материнская слава» медальләрен, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге «Ана даны – Материнская слава» медаленә таныклык һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләге «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү кәгазе бланкларын әзерләүне билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

4. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенә әлеге Указ белән расланган тасвирлама һәм форма (үрнәкләр) нигезендә «Ана даны – Материнская слава» медальләрен, Татарстан Республикасы дәүләт бүләге «Ана даны – Материнская слава» медаленә таныклык һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләге «Ана даны – Материнская слава» медале белән бүләкләү кәгазе бланкларын әзерләүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2010 ел, 22 июнь
№ ПУ- 397